Старлетамак, 2018

Я.С. Хисматуллин



# КЛАССТАШЛАР
# 1963 ел



Я.С.Хисматуллин

# КЛАССТАШЛАР,
# 1963 ел

Стәрлетамак, 2018 ел

Бу китапта Стәрлебаш районы Тәтер - Арслан урта мәктәбен 1963 елда тәмамлаучылар турында бәян ителә.

Алар үзләре турында үзләре язалар.

Китап төзүчесе:
Хисматуллин Я.С. һәм аның үз исәбенә чыгарыла.

# Немного истории...

Деревня Т – Арсланово была основана в 1739 – 1740 годах Арсланом Бикметовым и с тех пор она крепнет и растет. В 1813 году была построена красная мечеть, может быть и раньше на этом месте стояла мечеть, точно не известно. В 1908 году в деревне был открыт второй приход и мечеть. Рядом со второй мечетью было построено медресе из двух зданий. Таким образои, в деревне было две мечети и в обеих медресе преподавали детям основы исламских знаний. В медресе первой мечети преподавал Габсаттар Гатауллович Салаватов.

В 1917-18 годах в Т-Арсланово была открыта татарская школа, книги были на арабском языке. В 1918 – 1919 учебном году школой заведовал Амиржан Саубанович Рамиев. В 1924-1925 учебном году в школу из Стерлитамака прибыла молодая учительница Биби Ибрагимова.

В 1930 году правительством было введено обязательное начальное обучение и все дети школьного возраста были привлечены к учебе. В 1932-1933 учебном году в школу пришли молодые учителя Сабир Галиев, Гафур Латыпов, Сагит Рамиев. С 1928 года школа переходит на латинскую графику. В 1 - 4 классах количество учащихся достигает 210 человек. Когда ввели обязательное семилетнее образование в деревне была открыта семилетняя школа из 3 - 12 классных комнат. В этом виде она существовала с 1934 по 1959 годы. Первым директором семилетней школы был Мажит Хамитович. Мажит Хамитович проработал директором 5 лет. В 1937 году состоялся первый выпуск семилетней школы, ее окончили 18 человек.

15 августа 1940 года директором школы был назначен Сагит Лукманович Рамиев, в школу пришли новые учителя: Фатхи Рысаев, Султан Ишбульдин, Нуретдин и Фарида Шариповы.

С первых дней начала войны на фронт ушли Сагит Рамиев, Иванов, Нуретдин Шарипов, Фавзия Давлетшина, позже Гумар Масалимов, Таслима Алимбекова.

Зимой 1942 года директором школы был назначен Рахим Тайгунов.

Весной 1942 года, вернувшись раненым с фронта в школу пришел Давыдов Ахмет Салихович и был назначен директором школы – был единственным учителем с высшим образованием. Под руководством директора 11 учеников поехали в педучилище и в течении двух месяцев ознакомились с правилами преподавания. В 1943 - 44 учебном году девять учеников были назначены учителями начальной школы и приступили к обучению. Из них Майтап Рысаева (Баймуратова), Танзиля Атнашева, Сабиля Нугуманова долгие годы преподавали в школе.

26 октября 1942 года в школе начались первые уроки в 8 классе. Открытие средней школы заинтересовало жителей соседних деревень и в 1943 - 44 учебном году оттуда начали приходить учиться. С 1 го января 1944 года Тятер - Арслановская школа была включена в госбюджет и признана средней школой. В 1945 году школу окончили 5 человек, а в 1946 году 8 человек. С 1951 года директором школы работает фронтовик Анвар Гилязович Юнусов, он сумел организовать пришкольный участок, был заложен сад. Благодаря этому энергичному директору коллектив школы становится образцом для других школ.

В 1956 году директором школы стал Хафиз Гильманов. В эти годы коллектив школы обновился, прибыли молодые учителя Хайдар Рысаев, Савия Хисматуллина, Майсрур Киреева, Мунавара Махмудова, Тагир Арсланов, Мусавир Садыков, Галия Гадельшина, Январи и Раиса Федорова. В эти годы в школе обучались более 600 учащихся. В 1958 году директором был назначен Ярулла Агадуллович Зайнашев. Под его умелым руководством была начата работа по строительству нового здания школы, и она была построена в 1964 - 65 годах.

Весной 1965 года директором школы становится опытный педагог Салимов Хамза Камалетдинович. Под его руководством успешно реализовались задачи учебно - воспитательного процесса. Хамза Камалетдинович тесно сотрудничал со школой и после выхода на пенсию. В 1969 году количество



учащихся в Т - Арслановской школе превысило 800 человек, обучение велось в две смены. В школе работали 56 учителей, в пришкольном интернате жили более 100 учащихся из 28 деревень.

С 1983 года в школе работает музей боевой и трудовой Славы. Т-Арслановскую среднюю школу за 70 лет окончили более 2000 учащихся.

С 1994 года по 2005 год школу возглавил Ибрагимов Фанис Шарифуллович. С 2003 года школа отапливается природным газом. Арсланов Рамиль Хаевич – директор школы с 2005 года сумел организовать капитальный ремонт крыши школы.

С 2015 года школой руководит молодой, энергичный директор Арсланов Камиль Габдулхаевич. В Т-Арслановской средней школе трудится сплоченный педколлектив. Он состоял из 2х заслуженных учителей Башкортостана, 12 отличников просвещения РСФСР и РБ.

Краткая история Т-Арслановской средней школы взята из книги легендарного учителя этой школы Ярмухаметова Нагима Араслановича "Источник знаний и вдохновения" г.УФА 2009 г.

## Класс турында.

Без Т - Арслан урта мәктәбендә 10 классны, яки урта мәктәпне 1963 елда тәмамладык, 18нче чыгарылыш булып. Без класста 29 укучы укыдык һәм барыбызда урта мәктәпне уңышлы тәмамладык.

Безнең класста Т - Арслан авылыннан 7 укучы, Айдәрәледән - 6, Ибрайдан – 2, Айтуганнан – 1, К – Ярдан – 1, К – Юлдан – 1, Болгардан – 1, Яшерганнан – 3, Бузаттан – 7 укучы.

Без укыганда мәктәп директоры Зайнашев Я.А., класс җитәкчесе Арсланов Т.Х.

Укытучылардан: Завуч һәм немец теленнән Садыков М.Х., математикадан Махмудова М.М., рус теленнән Садретдинова Р.Н., химиядан Латыпова Ф.Ф., биологиядан Шахмуратова С.Л., татар теленнән Шарипова Ф.С., физкультурадан Ярмухаметов Н.А. укыттылар.




Аларның күбесе укучыларга төпле белем бирүгә ирештеләр.

Мәктәпне тамамлаучылар исемлеге:

1. Аглиуллина Нәзирә Биктимеровна.
1 сентябрь 1946 елда туган,
әлеге вакытта Т-Арслан авылында яши.
2. Адикаева Альфия Гараевна,
вафат.
3. Аллагулова Тәслимә Ибрагимовна,
әлеге вакытта Нуриман районында яши.
4. Арсланов Хусаин Хазигалеевич,
Татарстанның Нижнекамск шәһәрендә яши.
5. Арсланова Хәтимә Хамматовна,
Яшерган авылында яши.
6. Ахметова Насимә Абдрахмановна,
20 май 1946 елда туган, Карагуш авылында яши.



7. Ахмадеев Тагир Хуснуллович,
28 апрель 1946 елда туган, Уфа шәһәрендә яши.
8. Булатова Рәхимә Гилемзяновна,
әлеге вакытта Яшерган авылында яши.
9. Гайнетдинов Фанис Гайнуллович,
вафат.
10. Галиуллина Насимә Габитовна,
вафат.
11. Давлетъяров Галиаскар Сарварович,
25 январь 1946 елда туган, Стәрлетамак шәһәрендә яши.
12. Ибрагимов Фәнис Шарифуллович,
15 июль 1945 елда туган, Т - Арслан авылында яши.
13. Ишмухаметов Наиль Басырович,
Стәрлетамак шәһә-рендә яши.
14. Каримова Роза Ибрагимовна,
Благовещенск шәһәрендә яши.
15. Мавликаева Галия Сабировна,
11 март 1947 елда туган, Яшерган авылында яши.
16. Мифтахов Инсаф Загретдинович,
1 февраль 1946 елда туган, Толбазы авылында яши.
17. Муллагалеев Марс Закиевич,
13 сентябрь 1945 елда туган, Айдәрәле авылында яши.
18. Мулюкова Әнвәрә Шакуровна,
15 август 1945 елда туган, Куганакбаш авылында яши.
19. Низамутдинов Талгат Тимербулатович,
Бузат авылында яши.
20. Нугманов Мосавир Мигранович,
31 май 1946 елда туган. Стәрлетамак районында яши.
21. Рысаев Гафур Гаффанович,
вафат.
22. Садикова Назия, Бузат авылыннан.
23. Султанов Риза Каюмович,
1 ноябрь 1946 елда туган, Уфада яши.
24. Хабибуллина Гульшат,
Яшерган авылыннан.

25. Хамидуллин Фәрит Насипович,
вафат.
26. Хисматуллин Ягафар Саягфарович,
10 май 1946 елда туган,
Стәрлебаш авылында яши.
27. Шарипова Гулямза Матыйгулловна,
10 июль 1946 елда туган, Т - Арслан авылында яши.
28. Шахмуратова Минигуль Саббаховна,
Уфада яши.
29. Шигапова Миненур Каррамовна,
1 январь 1946 елда туган. Стәрлебаш авылында яши.

Класста староста булып Рысаев Г.Г. эшләде, комсорг булып Аглиуллина Н.Б. актив рәвештә эшләделәр. Мәктәп буенча комсомол оешмасын Хисматуллин Я.С. җитәкләде.

Безнең класс мәктәп буенча үткәрелгән барлык чараларда да актив катнаштык. Колхозда сезонлы үткәрелә торган эшләрдә (чөгендер утау һәм алу, салам эскертләү, малчылыкта мал абзарын тазарту һ.б.) катнашты.

Без, 9 классны тәмамлагач, районда һәм Республикада беренче булып стройотряд оештырдык.







Шушы стройотрядның тырышлыгы белән кыска срокларда мәктәп интернатын күчереп салдык һәм анда яңа уку елында укучылар яшәде.

Бу стройотрядта эшләделәр:

1. Ахмадеев Т.Х.
2. Гайнетдинов Ф.Г.
3. Ибрагимов Ф.Ш.
4. Нугманов М.М.
5. Рысаев Г.Г.
6. Хамидуллин Ф.Н.
7. Хисматуллин Я.С.

Мәктәпне тәмамлагач, арытаба очрашулар үткәреп тордык, бөтен класс белән һәрбер 5 ел саен, а арасында аерым классташлар очраша.

2017 елның җәй аенда Латыпова Фәридә апа (безнең хи-



мия укутычусы ) Уфада “ Нур” театры бинасында, үзенең 50 ләп Т-Арслан мәктәбен тәмамлаган укучыларын җыйды һәм зур, әчтәлекле очрашу үткәрде. Бу турыда “ Кызыл Таң ” газетасы зур мәкәлә язып чыгарды.

## Мәктәп директоры һәм аның хатыны.



**ЗайнашевЯруллаАгадуллович** родился 15.05.1922г. в дер. Акбердино Иглинского района БАССР. После окончания средней школы поступил и окончил учительские курсы в г. Наманган Узбекской ССР, в 1941 – 1942 гг. работал учителем географии в с. Касансай Наманганской области.

В ноябре 1942 г. призван в ряды Красной Армии из Узбекистана.

Участник ВОВ :

1. Оборона Москвы.
2. Курская Дуга.
3.Форсирование Днепра.
4.Штурм Кенигсберга.

В боях за взятие Кенигсберга тяжело ранен в голову, лечился в госпиталях, последний госпиталь в г. Пермь.

Фронтовые награды :

1.Медаль ” За боевые заслуги”.

2.Медаль ”За отвагу”.


3.Медаль ” За взятие Кенигсберга”.

Звание: Старшина ро-ты армейской разведки.

1946 – 1950 годы учеба в БГУ им. Тимирязева, географический факультет.

1950 – 1953 годы – директор и учитель географии в дер. Сахаево Кармаскалинского района.





1953 - 1959 годы – директор и учитель географии Сарайсинской средней школы Стерлибашевского района (дер. Елембетово ) – достроил школу.

1959 – 1965 годы – директор Тятер – Арслановской средней школы – построил школу.

1965 – 1968 г. Байгильдинская средняя школа Иглинского района – учитель географии.

(В 1965 году отец как бы приехал в свой, Иглинский район, до 1966 или 1967 г. Нуримановского района не было. После разделения Иглинского района на 2 района – Иглинский и Нуримановский мы оказались в Нуримановском районе).

1968 -1984 гг. – директор Нимисляровской 8 – летней школы Нуримановского района БАССР.

С 1987 по 1997 г. проживал в г. Омске.

Умер 29.04.1997г. похоронен в г. Омске.

# Рус теле һәм әдәбияте укытучысы.



**Зайнашева Роза Насретдиновна** (дев. фамилия Садретдинова) родилась в крестьянской семье в дер. Б - Кызылбаево Мечетлинского района 30.11.1927 года.

После окончания средней школы в 1946 – 1948 гг. поступила и закончила БГУ им. Тимирязева. (Учительский институт).

Трудовую деятельность начала в Сахаевской средней школе Кармаскалинского района учителем русского языка и литературы.





Далее работала в Сарайсинской, Тятер – Арслановской средней школах Стерлибашевского района. 1957 – 1961 гг. закончила Стерлитамакский пединститут заочно.

В 1963 г. награждена знаком Отличник Народного Просвещения РСФСР.

Далее работала учительницей русского языка и литературы в Байгильдинской, Нимисляровской средней школах. Умерла 31.12.2012 года, похоронена в г. Омске.

Дети - Ляля, Роберт, Ильдар. Внуки – Венера, Айдар.

# Безнең класс җитәкчесе:



**Арсланов Тагир Хабирович.**

Родился 22.06.1930 года в Тятер – Арсланове, окончил среднюю школу и учительский институт в г. Стерлитамаке, преподавал физику и математику в нашей школе. Он бессменный руководитель нашего класса, с 6 класса. Был очень обаятельным, мудрым, всезнающим педагогом. Благодаря его усилиям, стараниям наш класс был ведущим классом в школе. Нас было 29 человек в классе, большинство получило высшее и достигли больших успехов в жизни именно благодаря ему – нашему опытному наставнику, другу и человеку – Арсланову Тагиру Хабировичу.

**Мин Нәзирә Аглиуллина (Арсланова)** Тәтер – Арслан авылында Стәрлебаш районында 1 сентябрь 1946 елда туганмын. 1953 – 1963 елларда Тәтер – Арслан мәктәбендә укыдым. 1963 елның 1 сентәбреннән Аургазы районында Бәгәнәш авылында эшли башладым. 1964 – 1967 елларда Стәрлетамак медицина училищесында укыдым. 1967 – 1996 елларда Тәтер –



Арслан участок больницасында медсестра булып эшләдем. Тормыш иптәшем белән ике ул һәм бер кыз үстердек.

5 оныгым бар, 10 почет грамотасы. 1990 елда 1 категория, 1994 елда высшая категория, 1999 елда подтверждение высшей категории.

**Ахмадеев Тагир Хуснуллович,** родился 28 апреля 1946 года в д. Кабакушево Стерлибашевского района Башкирской АССР.

В 1963 году окончил Т-Арслановскую среднюю школу.



В 1963 - 1968 годах учился и окончил Башсельхозинститут, получил специальность инженер механик. В 1968 году был направлен гл. инженером в колхоз им. К.Маркса Стерлибашевского района, где проработал до августа 1969 года. Избирался секретарем комсомольской организации вышеуказанного колхоза.

В августе 1969 года переведен старшим инженером в отдел автотракторных запчастей Республиканского объединения "Сельхозтехника" Сов. Министров БАССР, где



проработал в различных подразделениях этой системы до 23 января 1986 года.

В январе 1986 года, после организации Государственного агропромышленного комитета БАССР, был направлен в Стерлибашевский район зам. Председателя районного агропромобъединения по механизации – директором Ремтехпредприятия.

В апреле 1987 года назначается 1 зампредседателя РАПО – директором ремонтно – технического предприятия, где проработал до 1991 года и в апреле 1991 года переводится 1 зам. Председателя исполкома Райсовета – нач. Управления с/хозяйства и продовольствия Стерлибашевского района, где проработал до апреля 1994 года.

В период работы в Стерлибашевском районе трижды избирался депутатом Стерлибашевского районного Совета народных депутатов.

Женат, имеет двоих детей: Ильдар и Ильмира, внук Дамир и внучка Милена.



В апреле 1994 года назначается начальником отдела по эксплуатации и обслуживанию газового хозяйства Минсельхозпрода РБ.

С августа 1994 года переведен зам. Генерального директора в Государственное кооперативное объединение "Башагропроммеханизация", где проработал до апреля 1996 года.

В апреле 1996 года был назначен начальником управления газового хозяйства АООТ "Башсельхозтехника", а с апреля 1997 года – зам. Технического директора по капитальному строительству и газовому хозяйству Государственного унитарного специализированного предприятия "Башсельхозтехника".

С декабря 1999 года по февраль 2002 года – зам.Генерального директора ОАО "Башсельхозэнерго".

С февраля 2002 года по август 2008 год главный механик, начальник АТЦ – 2 ОАО " Интеграл".

С 2009 года – 2017 г. – сотрудник управления собственной безопасности АО "Интеграл".

В 1992 году награжден Грамотой Верховного Совета Республики Башкортостан с присвоением звания "Заслуженный работник сельского хозяйства РБ". Ветеран труда. Имеет двоих детей. Проживает в г.Уфе.



Мин, **Арсланова Хәтимә Хәммәт кызы.** 1946 елны 18 январьда Стәрлебаш районы Тәтер – Арслан авылында доньяга килгәнмен. Авылымда 1963 нче елны урта мәктәпне тәмамладым. Стәрлетамакта 10 айлык пед.курсны тәмамлап, 25 ел Яшерган урта мәктәбенең интернатында тәрбияче булып эшләдем, хезмәт ветеранымын. Бер кыз үстердем, ике оныгым бар, бер оныкчыгым бар. Бүгенге көндә Яшерган авылында яшәп ятам, хаклы ялдамын.



## Үзем турында бер ничә җөмлә.



Мин, **Нәсимә Абдрахман кызы Әхмәтова,** 1946 нчы елның май аенда гади колхозчы гаиләсендә доньяга килгәнмен. Туган авылымда җидееллык белем алдым. Урта белемне күрше Тәтер – Арслан авылы мәктәбендә алдым. Гаиләдә белем алуга игътибар зур булды. Үзебез укый белмәгән чакта, әти үзе йөргән җирләрдән алып кайткан китапларны буш вакыт табып укырга тырыша иде. Ул китапларны хәтта ятлап бетерә идек.

Урта белем алганнан соң, шул ук елны үзем укыган мәктәпкә чакырып, операцияга китәргә тиеш булган Гомәр абыйның классын укытырга куштылар. Яңа елдан соң (1964 ел) өченче чирекне Түбәнге Ибрай авылында дәүләт имтиханнарын тапшырырга киткән Вәсилә апа классларын укытырга тәгаенләделәр.

Югары белемне читтән торып алдым.

Ул елларда колхозда бер тиен акча алмыйча эшләгән әти – әнигә алты балага белем бирү мөмкинчелеге юк иде. Озаккарак сузып булса да югары белемле булдым. Бер үк вакытта укытучылык эшен алып бардым, тәҗрибә тупладым. Тирә – ягымда олы йөрәкле, тырышлыгымны аңлый белгән укытучылар булып торды. Үзләре үз ярдәмнәрен тәкъдим иттеләр.

Турмай, Әйдәрәле, Карагыш мәктәпләрендә укыттым. Байтак еллар тәрбия эшләре буенча директор урын – басары вазыйфасын башкардым. Эшләгән эшләрем уңышлы бәяләнде. Башкортстан Мәгариф Министрлыгының, югары мәктәп, фәнни учреждение хезмәткәрләре профсоюзының Башкортстан өлкә комитетының Почет Грамотасы белән бүләкләделәр.

Шул елларда барлыкка килгән " өлкән укытучы " исеменә дә ул исем гамәлдән чыкканчы лаек булдым. "Югары категорияле укытучы", "Хезмәт ветераны" исемнәре дә эшемә тиешле бәя булгандыр.

Мәктәптә эшләгән елларымда ук төп эшемнең юлдашы булган иҗади эшемә хаклы ялга чыккач ныклап тотындым. Авыл халкы өчен төрле темаларга багышлап ял кичәләре оештыру мөмкинчелеге ачылды. Барысы 16 кичә үткәрелгән. Менә кайберләре: Карагыш авыл тарихына багышланган шәҗәрә бәйрәме, хезмәтләре белән дан казанганнарның юбилейлары, хәтер кичәләре, сабыйларга туу турындагы таныклыклар тапшыру ( район хакимияте башлыгы урынбасары Зәйтүнә Рыскулова, БР Министрлар кабинетының ЗАГСлар идарәсе җитәкчесе Рәшидә Солтанова, авыл биләмәләре эш башкаручылары һәм башка кунаклар чакырылган күргәзмә мероприятие иде ), колхозны аякка бастырып озак еллар буе алдынгылар рәтендә торган колхоз рәисе Мәгъзүр абый Рысаевның хәтер кичәсе, Мариус Максютовның хәтер кичәсе һәм башкалар.

Болардан тыш район күләмендә үткәрелгән "Ата – бабалар авазы" фестивалендә укылган "Җирдә якты нур калса" дигән шигырем "Гран – При" га лаек булды. Шул ук шигырем белән "Уртак язмыш" исемле шигыремә Нефтекама шәһәрендә үткәрелгән фестивальдә дә диплом бирелде.

2014 елда Мәдәният елына багышланган район марафоны дипломын иҗади эшләремнең бәясе итеп кабул иттем.

Шул ук елда Республикабызның "Берлек" төбәк татар



иҗтимагый мәдәни – агарту оешмасы җитәкчесе Рөстәм Гыйльметдинов култамгасы белән "Халык хәтерен саклап" исеме белән тәү тапкыр үткәрелгән крайны өйрәнүчеләр конкурсының җиңүчеләре бүләкләнде.

Тарихи дәреслекне кайтару максаты белән башланган донья күләм эштә " Карагыш кичергән давыллар" исемле китабым Республика буенча ул вакытта җыелган 110нан артык китап арасыннан өченче дәрәҗә дипломга лаек дип табылган. Акчалата премия дә бирелде. Болар Уфага чакырылып бирелде. Ә аннары Казанда үткәрелгән форумга делегат булып бардым.

Моннан байтак еллар элек Муса Җәлилнең Казандагы квартира – музеенда һәр ике ел саен аның туган көнендә "Җәлил укулары" үткәрелә башлаган. 2012 нче, 2016 нче елларда миндә шул тантанага чакырылдым һәм анда катнашырга насыйп булды. Моннан соң да чакыру көтеп тормыйча ук, почетлы кунак булып бара алам.

2015 нче елда Татар Каргалысында үткәрелгән 6 нчы Бөтенрусия авыл сабантуенда катнаштым. Уфа – Казан – Болгар – Уфа маршруты буенча ике ел рәттән теплоходта сәяхәт иттем. Изге Болгар җиренә аяк басарга, мәңгелекне борынгылык белән тоташтырган сукмаклардан үтү бәхетенә ирешергә насыйп булды. Рәхмәт язмышыма. Барысында да уңышка ирештермәсә дә, яшәүнең иң мөһим кыйммәтләреннән мәхрүм итмәгәне өчен рәхмәтлемен. Шушы сәяхәтләрнең икесендә дә укылган шигырләремә беренче урын биргән иде.

Биш китабым донья күрде. Ике шигырьләр китабы, икесе авыл уңганнарына багышланган. Берсе халык хәтерендә сакланган истәлекләр буенча язылган авыл тарихы. Алтынчы китабым да бастырырга әзер.

Гаиләбездә ике ул үсте. Икесе дә үз көчләре белән югары белем алды. Алган белемнәре буенча эшлиләр. Гаиләлеләр. Биш оныгыма сөенеп яшим.

## Җавапсыз сорауларым.

Килдем нигә бу дөньяга?
Ни өчен әле яшим?
Шушы сорауларга җавап
Эзләми булмас кеше.
Көн дә тапалган сукмактан
Чыгалдыммы зур юлга ?
Сулга бару җиңел чакта
Борылалдыммы уңга?
Ярдәм кулын сузалдыммы
Торганга юл читендә?
Чаткы дөрләтә алдыммы
Пыскып яткан утында?
Кирәк сүзне әйтәлдемме
Яклау көткән кешемә?
Игътибарым җитте микән
Картына һәм яшенә?
Кеше булып калалдыммы
Мәхшәр тулы дөньяда?
Тырыштыммы тапалмаска
Ялган аяк чалганда?
Күп мәгълүмат арасыннан
Сайладыммы кирәген?
Аңымны да, эшемне да
Яктыга этәргәнен.
Тырыштыммы нәсел исемен
Тап төшерми сакларга?
Өйрәттемме балаларны
Дөреслекне якларга?
Зур бәхет, диләр, кешегә
Кирәк булып яшәүдә.
Бер кемгә дә кирәкмәсәң
Мәгънә бармы яшәүдән?
Ник яшәдем? Ни калдырам
Эчкән суым хакына?



Мин яшәүдән берәр файда
Булды микән халкыма?
Өйрәттемме балаларга
Максат белән яшәргә?
Яшьтән омтыл, дип, тормышта
Үз урының табарга.
Ныкышмалы булдым микән
Максатка ирешкәндә?
Ни дип искә алыр кеше
Исләренә төшкәндә?
Кызармасмы минем өчен
Бала – туганнар йөзе?
Менә шулар тыңгы бирми
Җиткәндә гомер көзе.
Яшәгән саен арталар
Җавапсыз сорауларым.
Җавапсыз сорауларыма
Кайчан җавап табармын?!

## Саумы, Белем бәйрәме.

Саумы беренче сентябрь,
Саумы, белем бәйрәме.
Сине котлый яше – карты
Бүләк – гөлләр бәйрәме.
Хуш киләсең доньядагы
Мәртәбәле олы көн.
Битараф түгел берәүдә,
Дулкынланмый бүген кем?
Синңа китергән сукмактан
Олы юлга чыгабыз.
Кеше булып яшәү юлын
Тик мәктәптә табабыз.
Төшендерә мәктәбебез
Күп серенә дөньяның.
Рәхмәтебез чиксез синңа,
Шуңа югары даның.

## Хуш, мәктәбем.

Белем чишмәң бик шифалы,
Диңгез кебек таша уйларым.
Вакыт җитте эшкә җигелергә
Сау бул, мәктәп, сау бул, укытучым,
Бала чагым, гамьсез елларым.

Төнне ярып аткан таң шикелле
Син яктырттың тормыш юлларын.
Белем канатында очам хәзер.
Сау бул, мәктәп, сау бул, укытучым,
Хыялый үсмерчак елларым.

Мәктәп елларыбыз артта калды,
Җыелыштык соңгы кичәгә.
Һәркем тоя үзен әзер итеп
Таулар, диңгезләрне кичәргә.
Оныталмам, укытучым, мәңге
Бәхетле бул, диеп әйткәнең.

Яшь аралаш кабатлыймын тагын
Хуш, мәктәбем, сау бул, мәктәбем.
Әлифбаның хәрефләре аша
Сукмак салдык яшәү серенә.
Әнкәемдәй иң кадерле кеше –
Укытучым – күңел түрендә.

Ышан, мәктәп, синең исемеңә
Тап төшерми яши белермен.
Юл чатында әгәр торып калсам,
Киңәш сорап сиңа килермен.



## Укытучым.

Һәр баланың йөрәгенә
Урау – урау юллар итә,
Шул юлларны таба белгән
Синең акыл – көдрәтеңә
Мин сокланам, укытучым.
Күпме гомер кичерсәк тә
Күңел һаман тылсым кошы,
Сине табам яхшылыктан,
Сабырлыктан, батырлыктан,
Гадилектән, матурлыктан,
Рәхмәтем зур, укытучым.

## Соңгы кыңгырау.

Дәшә серле юллар, башта төрле уйлар
Яшь йөрәкне борчый мең сорау.
Якты юллар теләп, яхшылыкка өндәп,
Саубуллаша көмеш кыңгырау.
Ямансу да икән аерылуны белеп
Урамнарны җырлап бер урау.
Көмеш тавыш тынмый, колакларда чыңлый
Соңгы тапкыр чыңлый кыңгырау.
Май кояшы иркә нурландыра
Алып килгән чакта җылылык,
Без мәктәпкә бүген тантаналы
Соңгы кыңгырауга җыелдык.
Мәктәп, мәктәп, синдә укыганда
Купме кыңгыраулар ишеттек.
Тупсаң аша атлап керү белән
Безне якын күрдең, иш иттең.
Әйдә зыңла, гүлә, суз җырыңны,
Беләм, монсы соңгы кыңгырау.
Зың – зың җырың минем тормышымда
Тансык бер җыр булып яңгырар.

# МӘКТӘП ЕЛЛАРЫ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Айдәрәледә беренче белем учагы булган мәдрәсәнең унсигезенче гасырның соңгы егерме – утыз елында ачылган булуы билгеле. Өйләре зуррак кешеләргә урнашкан тәүге мәдрәсәләр. Тәүге мәчетнең 1908нче елда салынуын авыл тарихы битләреннән укып белергә була. Икенче мәчет Яңа авылда, ягъни Яңа Айдәрәледә 1914нче елда ачыла. Ә менә башлангыч белем бирүче яңача укытылу 1920нче елдан исәпләнә. Әнә шул мәчет мәдрәсәләрне мәктәп итеп файдалана башлыйлар. Без укый башлаган елларда, аларны сүтеп яңа мәктәп төзеделәр. Ташкоймалары нигез салуга файдаланылгандыр инде. Таш-кырчыннарын җыярга, җирне тазартырга, түтәлләр ясап чәчкәләр, яшелчәләр чәчәргә кирәгәчәк. Төрле җимеш агачлары, куаклар утыртачакбыз. Без укый башлаган елларда да әле мәктәп башлангыч белем бирү мәктәбе булган. Ә без инде монда җидееллык белем алып чыктык.

Без икенче класста укыганда мәктәп директоры булып әниебезнең авылдашы һәм якын гына туганы Нәүрүзбәк Ибраһим улы Рәхимов эшли башлый. Хатыны Мәхмүдә апа безне укыта. Мәхмүдә апаның бер үзенчәлекле педагогик алымы истә гомерлеккә калды. Мин ул алымны үземнең практикамда да уңышлы кулландым. Бакирова Галия белән икәү түбән классларда гел бишкә укыдык. Ә ул елларда матур язу дәресе бар иде. Дәрес буена бер яки ике элементны дөрес язу күнекмәләре үткәрелә, ягъни дөрес каллиграфия булдырыла. Укытучыбыз безне, тагын да тырышыбрак укысыннар диеп күрәсең, ярыштыра: беребезгә бишле, икенчебезгә дүртле куя. Югыйсә, (безнең карашка инде) икебезнең язу да бер тигез. Безнең ризасызлык белдереп, борыныбызны салындырып, иптәшебезнең дәфтәренә астан гына кырын күз салгалап утырганны абайлап алган апабыз икенче дәрескә икебезгә дә бер төрле билге куя. Белемебезне “тигезли”. Борын салындырырга урын калмый. Икебез тагы да тырышыбрак бишлегә өмет белән язабыз. Мин моның үзенә күрә уңышлы



алым икәнен үзем эшли башлагач та аңладым.

Менә шулай, шыгырдап торган бүрәнәләрдән салган өр-яңа мәктәбебез бар. Тирә-ягын ихаталап алганда безнең ярдәм тагын кирәкте. Балалар санына карап, һәр класска багана утыртыр өчен чокырлар казу урыны бүлеп бирелә.

Бакчадагы бар нәрсәне утырту, үстерү серләрен биология укытучысы Әминә апабыздан өйрәнәбез. Яз көне анютины глазки исемле әллә ничә төрле чәчкә ата торган, кар төшкәнче чәчкә атып утыручы чәчкәләр утырттык. Безнең аны беренче күрүебез иде. Түттәләрдә иң тәмле яшелчәләр үсте. Җәй буе елгадан су ташып сиптек, чүпләрен утап тордык. Авылда яшәү өчен мөһим булган күп һөнәрләрдә өйрәндек бу бакчада эшләп.

Мәктәп йортында физкультура дәресләре өчен махсус урын булдырылды. Турникта күтәрелергә өйрәндек. Ике “галәмәт биек” багананы аркылы агач белән тоташтырып утырткач, ике бау тактылар да очларына кулча беркеттеләр. Шунда күтәрелеп “мускуллар ныгытабыз”. Ерактанрак йөгереп килеп озынлыкка сикерер өчен пычкы чүбе таратылган аерым урын билгеләнде. Бу эшләрнең барысы да физкультура белән хезмәт дәресләрен укытучысы Хабибнасов Мирсәет Мирвәиз улы җитәкчелегендә эшләнде. Монда инде мәктәп укучылары гына түгел, авыл яшьләре дә килеп эшләште. Мәйданчык әзер булгач, үзләре дә кичләрен уйнарга шунда җыелалар иде.

# ЛИКЕР САЛУДАН “КАЧЫП” КАЛДЫК.

Мәктәпне көнбатыш ихатасы зират буйлап сузылган. Ихатаның эчке ягына кыш буе яга торган утын өелә. Шул утын агачларының озынрак булып чыгып торганнары безнең таган атынып уйный торган аулак урын. Без анда хәттә барыбызга да мәҗбүри рәвештә ликер ясаучы врач апалардан да качып кала идек.

Беркөнне Тәслимә Галиуллина дәрескә килгәч тә, бүген ликер салырга киләләр, дигән хәбәрне шыпырт кына кызларга әйтте. Бер дәрестән соңдырмы, икәүдәнме, берничә